| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**13.06.2019** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 249** |

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге тарафыннан алынган башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны җибәрү турында

«Зеленодольск муниципаль районы Финанс – бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дегтева мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 28 мартындагы 233 номерлы карары нигезендә, "Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы" муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дегтева, «Җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында " Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 26 апрелендәге 379 номерлы карары нигезендә Зеленодольск шәһәре Советы карар чыгарды:

1. "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерүне финанслар белән тәэмин итүгә һөнәри керемгә салым бенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатыннан чыгып, "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге тарафыннан алынган башка бюджетара трансфертлар хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен расларга.
2. «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге тарафыннан һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында алынган башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы «Зеленодольск

муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 52нче статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиеш.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет " мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**